**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ____________ ПГ-10 14.03.2024 КАРАР №____

Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 24, 28 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законы, район Уставы, Актаныш районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы авыл җирлекләренең Генераль планнарын эшләү турында» 2021 елның 23 апрелендәге ПР-73 номерлы карары нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.
2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Актаныш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.
3. «Актаныш таңнары»газетасында ачык тыңлаулар үткәрү турында мәгълүматны бастырып чыгарырга.
4. Ачык тыңлауларны үткәрү вакытын 1 көн дип билгеләргә.
   - ачык тыңлауларны үткәрү вакыты - 2024 елның 18 апреле:
   - 10.00 сәгатьтә, үткәрү урыны: Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 17 йорт, 17 кабинет.
5. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы А.К.Галиәхмәтовны ачык тыңлаулар үткәрү өчен җаваплы итеп билгеләргә.
6. Актаныш авыл җирлегенең генераль планы проекты турында фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен, кушымта нигезендә расларга.
7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район Башлыгы Л.Р.Зарипов

Актаныш муниципаль районы
Башлыгы карарына
_______ 2024 ел, №____
кушымта

АКТАНЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ГЕНЕРАЛЬ ПЛАНЫ ПРОЕКТЫН ТИКШЕРҮДӘ ГРАЖДАННАРНЫҢ КАТНАШУ ТӘРТИБЕ

Әлеге Тәртип Актаныш авыл җирлегенең генераль планы проекты (алга таба Генераль план) буенча фикер алышуда халыкның катнашуын тәэмин итү максатыннан эшләнгән һәм авыл җирлеге гражданнарының Генераль план проекты буенча фикер алышуда катнашу тәртибен, шулай ук Генераль план проекты буенча халык фикерен исәпкә алу тәртибен җайга сала.

1. Генераль план проекты буенча гражданнарның фикер алышуда, Генераль план проекты буенча ачык тыңлауларда катнашуы һәм авыл җирлегендә яшәүчеләрнең Актаныш районы Башкарма комитетына язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү юлы белән башкарыла.

2. Җирлекнең генераль планы проектының график һәм текст материаллары экспозициясе Актаныш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырылган.

3. Җирлекнең генераль планы проекты материаллары белән танышу вакыты: дүш. - җом. - 9.00дән 16:00гә кадәр, (төшке аш вакыты 11.30 дан 13.00 гә кадәр).

4. Генераль план проекты территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында fgis.economy.gov.ru рәсми басылып чыгарга тиеш.

5. Җирлекнең генераль планы проекты буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул итү түбәндәге адрес буенча гамәлгә ашырыла: 423740, ТР, Актаныш ав., Ленин пр., 17 й., Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы, инфраструктур үсеш бүлеге;

6. Ачык тыңлауларны әзерләү һәм уздыру, шулай ук Генераль план проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итү һәм исәпкә алу ачык тыңлаулар уздыру өчен җаваплы.

7. Генераль план проекты буенча фикерләрне, тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алуны документлар белән тәэмин итүне ачык тыңлауларны үткәрү секретаре гамәлгә ашыра.

8. Ачык тыңлаулар башланганчы секретарь тарафыннан ачык тыңлауларда катнашучыларны теркәү башкарыла. Теркәлү битендә ачык тыңлауларда катнашучыларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны адресы күрсәтелә.

10. Ачык тыңлаулар уздырганда түбәндәге регламент билгеләнә:
- докладчыга төп доклад өчен 20 минуттан да артык бирелми;

- җирлекнең Генераль планы проекты буенча фикер алышу буенча чыгышлар өчен 3 мин тан артык түгел;

- репликалар һәм искәрмәләр өчен - 2 минуттан артык түгел.

11. Ачык тыңлаулар уздырганда секретарь тарафыннан Генплан проекты буенча ачык тыңлаулар беркетмәсе алып барыла. Беркетмәне ачык тыңлауларны оештыручы һәм секретаре имзалый.

12. Ачык тыңлауларны оештыручы ачык тыңлаулар уздырылганнан соң, 2 көн эчендә, ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча йомгаклау әзерли, анда мәҗбүри рәвештә түбәндәгеләр күрсәтелә:

- ачык тыңлауга чыгарылган сорауның исеме;
- ачык тыңлаулар уздыру датасы, вакыты һәм урыны;
- ачык тыңлауларда катнашкан авыл җирлеге гражданнары саны;
- ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча карар.

14. Бәяләмәгә ачык тыңлауларны оештыручы имза сала һәм ачык тыңлаулар беркетмәсе белән бергә “Актаныш таңнары” газетасында, районның рәсми сайтында, Актаныш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һичшиксез бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.